| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Девятернинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Девәтернә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2025 Девәтернә авылы № 6-2

Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советының 2024 елның 28 октябрендә кабул ителгән 50-1 нче номерлы «Физик затларның милек салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Салым кодексына, 2025 елның 28 ноябрендә кабул ителгән 425-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең закон актларын (закон актларының аерым положениеләрен) гамәлдән чыккан дип тану турында»гы Федераль законына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 2024 елның 28 октябрендә кабул ителгән 50-1нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 6 пунктчасында «күп фатирлы йортлар өчен каралган төзелеш объекты булмаган очракта;» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында https://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга, шулай ук Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Э.Э. Ганиев

Совет Девятернинского сельского поселения
Девәтернә авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002646